ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.05.2023 Олы Кайбыч ав. № 190

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 апрелендәге 390 номерлы карары белән расланган «2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе демографик сәясәт концепциясен раслау турында» 2007 елның 09 октябрендәге 1351 номерлы, «Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 07 маендагы 204 номерлы Указлары нигезендә Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 апрелендәге 390 номерлы карары белән расланган «2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы халкы арасында иҗтимагый сәламәтлекне ныгыту» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Максатлар» юлына түбәндәге эчтәлекле өченче пункт өстәргә:

«3. Кайбыч муниципаль районы территориясендә район халкы санын тотрыкландыру һәм демографик үсешкә алшартлар тудыру»;

- «Бурычлар» юлына түбәндәге эчтәлекле дүртенче пункт өстәргә:

«4. туучылар санын арттыру.»;

- муниципаль программага кушымтага түбәндәге эчтәлекле алтынчы бүлек өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «VI. Туучылар санын арттыру чаралары | | | | | | |
| 6.1. | Йөкле хатын-кызларны иртә исәпкә кую | 2023-2024 | - | - | - | «Кайбыч үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча) |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.2. | Хроник авырулар белән интегүче йөкле хатыннарны шифаханә-курортларда дәвалану белән тәэмин итү | 2023-2024 | - | - | - | «Кайбыч үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча) |
| 6.3. | Йөкле хатын-кызларны өстәмә тимер препаратлары һәм витаминнар белән тәэмин итү | 2023-2024 | - | - | - | «Кайбыч үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча) |
| 6.4. | «Яшь аналар мәктәбе» эше | 2023-2024 | - | - | - | «Кайбыч үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча) |
| 6.5. | Авыр тормыш хәлендә калган йөкле хатын-кызларга социаль тәэмин итүне дә кертеп, медицина-социаль ярдәм күрсәтү | 2023-2024 | - | - | - | «Кайбыч үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча), Социаль яклау бүлеге (килешү буенча) |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http:/kaybici.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров